ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ОТАРСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ОТАРКА АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

ул.Октябрьская, д.17, с. Отарка,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422180

Октябрь ур., 17 нче йорт, Отарка авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422180

тел.(факс): (85563) 4-05-07; e-mail: Otar.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Постановление
от «31» 01. 2022 ел.

Карар
№7

Татарстан Республикасы Мамадыш
муниципаль районы Отарка авыл җирлегендә
җирләү буенча гарантияле исемлек
нигезендә хезмәт күрсәтү бәясен раслау турында

“Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 нче елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законы, “Күмү һәм җирләү эше турында” 1996 елның 12 нче гыйнварындагы 8-ФЗ санлы Федераль законы, “Татарстан Республикасында “Күмү һәм җирләү эше турында” Федераль законны тормышка ашыру чаралары хакында” 2007 ел, 18 май, 196 нчы карары, Россия Федерациясе Дәүләт Хакимиятенең “2022 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү коэффициентын раслау турында" 2022 елның 27 гыйнварындагы 57 санлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Отарка авыл җирлеге Башкарма комитеты

к а р а р б и р ә:

1.Мамадыш муниципаль районы Отарка авыл җирлегендә җирләү буенча гарантияле исемлек нигезендә хезмәт күрсәтү бәясен 1 нче һәм 2 нче кушымталар нигезендә 6964,68 сум күләмендә билгеләргә һәм 2022 нчы елның 1 февраленнән гамәлгә кертергә.

- Мамадыш муниципаль районы Отарка авыл җирлеге Башкарма комитетының 29.01.21 ел, № 4 карарын гамәлдән чыгарырга

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында һәм массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен үз контролемә алам.

Җитәкче И.И.Фазылов

Татарстан  Республикасы Мамадыш
муниципаль районы Отарка авыл җирлеге
Башкарма комитетының
31.01.2022 ел, 7 нче санлы карарына
1 нче № кушымта

2022 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы Отарка авыл җирлегендә җирләү  буенча
гарантияле исемлек нигезендә тормыш иптәше, якын туганнары, законлы
вәкиле булган очракта, хезмәт күрсәтү бәясе

| Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтү бәясе (сумнарда) |
| --- | --- |
| Җирләү өчен документлар әзерләү | 0,00 |
| Гүргә иңдерүгә кабер такталары, табут һәм башка предметлар бирүгә һәм китерүгә | 3203,78 |
| Мәетне (мәет калдыкларын) зиратка алып килүгә | 834,79 |
| Кабер казу һәм җирләү | 2926,11 |
| барлыгы | 6964,68 |

Җитәкче И.И.Фазылов

Татарстан Республикасы Мамадыш
муниципаль районы Отарка авыл җирлеге
Башкарма комитетының
31.01.2022 ел, 7 нче номерлы карарына
2нче № кушымта

2022 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Отарка авыл җирлегендә җирләү буенча гарантияле исемлек нигезендә, тормыш иптәше, якын туганнары, законлы вәкиле булмаган очракта,хезмәт күрсәтү бәясе

| Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтү бәясе (сумнарда) |
|---|---|
| 1.Җирләү өчен документлар әзерләү | 0,00 |
| 2. Мәетне киендерү | 993,95 |
| 3.Гүргә иңдерүгә кабер такталары, табут һәм башка предметлар бирүгә һәм китерүгә | 2300,80 |
| 4.Мәетне (мәет калдыкларын) зиратка алып килүгә | 851,70 |
| 5.Кабер казу һәм җирләү | 2818,23 |
| барлыгы | 6964,68 |

Җитәкче И.И. Фазылов